ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.09.2017 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2489**

«Айныткыч» муниципаль автоном учреждениесен ябу(ликвидацияләү) турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы, 2006 елның 3 ноябрендәге «Автономияле учреждениеләр турында» 174-ФЗ номерлы,1996 елның 12 гыйнварындагы «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 7-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, шулай ук «Айныткыч» муниципаль автоном учреждениесе эшчәнлеген гамәлдәге законнар нормаларына китерү буенча Зеленодольск шәһәр прокуратурасының таләпләрен үтәү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 июлендәге 1661 номерлы «Авыр исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү буенча Зеленодольск үзәген булдыру турында» гы карары белән төзелгән «Айныткыч» муниципаль автоном учреждениесен ликвидацияләргә.
2. «Айныткыч» муниципаль автоном учреждениесен ябу чараларын үткәрү өчен «Айныткыч» МАУ җитәкчесе - Ибраһимов Илдар Исмәгыйль улын ликвидатор итеп билгеләргә.
3. «Айныткыч» муниципаль автоном учреждениесе ликвидаторына:

- өч көн эчендә салым органына юридик затларның бердәм дәүләт реестрына юридик затның ябу процессында булуы турында белешмә кертү өчен «Айныткыч» муниципаль автоном учреждениесен ябу турында карар кабул итү турында язмача хәбәр итәргә;
- биш көн эчендә билгеләнгән тәртиптә «Айныткыч» муниципаль автоном учреждениесен ликвидацияләү турында, аның кредиторлары таләпләрен белдерүнең тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат бастырырга, шулай ук кредиторларга аны ликвидацияләү турында язма рәвештә хәбәр итәргә;
- раслау өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына арадаш ликвидация балансын тапшырырга;

- кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамлангач, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына раслауга ахыргы ликвидация балансын тәкъдим итәргә;

- әлеге карар нигезендә ликвидацияләнә торган «Айныткыч» муниципаль автоном учреждениесенең хезмәткәрләренә гарантияләрне һәм компенсацияләрне үтәүне тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитетына «Айныткыч» муниципаль автоном учреждениесенең юридик затларын Бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында таныклык тапшырырга;

-2017 елның 31 декабренә кадәр «Айныткыч» муниципаль автоном учреждениесен ликвидацияләү процедурасын төгәлләргә.

4. «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесенә законнарда билгеләнгән тәртиптә «Айныткыч» муниципаль автоном учреждениесе мөлкәтен кабул итәргә.

5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 01 мартындагы«Исерек хәлендә булган һәм әйләнә-тирә мохиттә үз-үзен йөртү яки ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга «Айныткыч» МАУда хезмәт күрсәтү тәртибен раслау турында» 03-03-383 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.В.Старостинга йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин